РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел./факс +7(84396) 2-59-00, email: cheremshan@tatar.ru, http://cheremshan.tatarstan.ru

27.10.2022 ел №142

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Советы
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча территориаль өчьяклы комиссия турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2022 елның 28 июлендәге 127 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Татарстан Республикасында социаль партнерлык органнары турында» 2004 елның 26 июлендәге 42-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, социаль партнерлык яклары тәкъдимнәрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча территориаль өчьяклы комиссия турында нигезләмәне раслау хакында» 2022 елның 28 июлендәге 127 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 2.1 пунктның 2 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә: «2.1. Комиссиянең саны һәм персональ составы Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан раслана».

1.2. 2.3 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә: «2.3. Җирле үзидарә органнары вәкилләрен раслау һәм алыштыру Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан башкарыла».

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны торак мәсьәләләре, социаль сәясәт, сәламәтлек саклау, мәгариф, мәдәният, яшьләр сәясәте һәм спорт буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль район<br>
башлыгы урынбасары,<br>
Совет рәисе урынбасары — Г.М. Җамалетдинов